# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегенең Яңа Кокшан торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү турында

15.11.2025 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2035 елның 20 март 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге башлыгының “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегенең Яңа Кокшан торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” 2025 елның 1 ноябрендәге 7 нче номерлы карары нигезендә

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. “2026 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегенең Яңа Кокшан торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Ушковлар урамына 700 метр арага вак таш салу, илтеп җиткерү һәм тигезләү);

2) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (МТЗ-82 тракторы өчен чапкыч сатып алу);

3) янгынга каршы резервуарлар (янгын сулыклары), янгын машиналарына су алу урынын төзү, ремонтлау (янгын машиналарына су алу урынын төзү документациясен рәсмиләштерү)?»

2. Карар кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Монашево авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru “Монашево авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Монашево авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Иосифов